# Заманча педагогик технология буларак проектлар методы. Аны татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә куллану

Абдукаева Гөлия
Габделхай кызы

***Проектлар методы*** - нинди дә булса проблеманы өйрәнү һәм гамәли нәтиҗәсен күрсәтү өчен укучыларның мөстәкыйль эшчәнлегенә нигезләнгән укыту методы






уку-укыту процессын оештырудагы яңа төрле алым

укучының мөстәкыйль эшчәнлеге

субъект-объект мөнәсәбәте

уртак бер нәтиҗәгә килү


Укытучының
роле -
юнәлеш,
этәргеч бирү



Укыту-
тәрбия
процессы
нигезендә
укучының
мөстәкыйль
эшчәнлеге
ята

## *Проект эшчәнлегенең бурычлары:*

- укучыларда интеллектуаль һәм гомумхезмәт белемнәрен булдыру, аларның хезмәт нәтиҗәләрен күз алдына китереп эшләрлек күнегүләр белән тәэмин итү;
- иҗади фикерләү, мөстәкыйльлек һәм башлап эш итү сәләтен үстерү;
- укучыларны мөстәкыйль рәвештә мәгълүмат җыярга, уйларга, анализ ясарга өйрәтү.
- укучыларда әдәбият өйрәнүгә теләк уяту;
- укучыларның иҗади мөмкинлекләрен камилләштерү;
- укучыларның фән буенча белемнәрен тирәнәйтү;

**Бүгенгесе көндә татар теле һәм әдәбиятын проектлар методы кулланып укыту**

**белем бирү процессының нәтиҗәлелеген арттыра**

**укучыларны киләчәк тормышка әзерли**

укыту нәтиҗәләре өчен җаваплылык өсти

белем алуга кызыксыну уята

***Проект эшчәнлеге укучыда төрле гамәлләр формалаштыра*.**

Шәхси УУГ

Коммуникатив УУГ

Регулятив УУГ

Танып-белү УУГ


проект
Монопроект
Фәнара проекты
Төп уку фәннәреннән тыш булган проект

## *Проект эше түбәндәге этаплардан тора:*

- тема тәкъдим ителә;
- юнәлеше, максаты, бурычы аңлатыла;
- үтәү вакыты билгеләнә ;
- башка сыйныф укучыларының иң яхшы эшләре күрсәтелә;
- проект эшенең планы төзелә ;
- укучылар үзләрен кызыксындырган шәхси биремне сайлыйлар;
- укучы шәхси бирем буенча материал эзли, җыя;
- йомгаклау дәресендә проект эше ялгана;
- чыгышларның планы төзелә;
- проект эшен яклау оештырыла

# Проект «Татар фольклорында буре образы»

1 нче төркем: бүре образы булган татар халык әкиятләрен өйрәнде;

2 нче төркем: рус халык әкиятләрен өйрәнде;

3 нче төркем: бүре сүзе кергән мәкаль һәм әйтемнәрне өйрәнде;

4 нче төркем: “Ак бүре” әкиятен өйрәнеп  бүре образына характеристика бирде.



# Проект «Яңа ел бәйрәме»

- Яңа елны каршылау;
- Яңа ел кичәсе өчен костюмнарны презентацияләү;
- Яңа ел табыны;
- Котлау открыткасы. Чакыру кәгазе язу



Әлеге методны кулланганда педагог бик ныклап проектка әзерләнсә дә, проектның биремнәрен эшләү барышында ул күзәтүче һәм юнәлеш бирүче роленә күчә.

Шулай итеп, проектлар методын кулланып уздырган дәресләрдә укучылар укытучыга караганда күбрәк эшли булып чыга.

## Проект эшчәнлегенең унай яклары :

1.Укучы төрле формада эш алымнарын файдаланып, хезмәтен тәкъдим итәргә өйрәнә

- 2.Теләсә кайсы чыганактан файдалану күнекмәсе формалаша, кызыксынучанлыгы арта;
- 3. Йомшак укучылар да читтә калмый, белем үзләштерүдәге кыенлыкларны җиңәргә өйрәнә;
- 4. Аудитория алдында чыгыш ясарга, үзенең эшен сыйфатлы итеп күрсәтергә күнегә.